**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 4 сентябрендәге 3101 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

Яшь педагогларны һөнәри яктан үстерү, аларның социаль статусын күтәрү, шәхес буларак формалаштыру, үз-үзләрен камилләштерү һәм мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру, укытучы һөнәренең абруен күтәрү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов) муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә конкурсны гамәлгә ашыру буенча чыгымнарны Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең 2026 елга бюджет исемлеге чикләрендә башкарырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 4 сентябрендәге
3101 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагоглары арасында конкурс (алга таба – Конкурс) оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

1.2. Конкурста педагогик эшчәнлек стажы кимендә бер елны тәшкил иткән, төп эш урыны Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе булган, узган елгы Конкурста җиңү яуламаган 30 яшькә кадәрге яшь педагоглар (алга таба – яшь педагоглар) катнаша.

1.3. Конкурс Казан шәһәренең мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш кертергә сәләтле яшь педагогларның һөнәри яктан үсүе өчен шартлар тудыру, яшь педагогларның социаль статусын күтәрү, аларны шәхес буларак формалаштыру, үз-үзләрен камилләштерү һәм мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру, укытучы һөнәренең абруен күтәрү максатыннан уздырыла.

1.4. Конкурсны оештыручы – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе (алга таба – Вәкаләтле орган).

## II. Конкурсны уздыру тәртибе һәм вакыты

2.1. Конкурс уздыру турында белдерү әлеге Нигезләмәне раслаган көннән алып өч эш көне эчендә Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең өстәмә битендә (https://obrazovanie.kzn.ru) урнаштырыла. Белдерүдә түбәндәге мәҗбүри мәгълүматлар булырга тиеш:

- документларны тапшыру вакыты, урыны һәм тәртибе;

- Конкурста катнашучылар тарафыннан гаризаларны тапшыра башлау һәм аларны кабул итүне тәмамлау даталары;

- Конкурста катнашучыларга карата таләпләр һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүләрен раслау өчен Конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге;

- Конкурста катнашучылар тарафыннан гаризаларны тапшыру тәртибе һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган гаризаларның формасына һәм эчтәлегенә карата таләпләр;

- Конкурста катнашучыларның гаризаларын кире алу тәртибе, Конкурста катнашучыларның гаризаларын кире кайтару, шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кире кайтару өчен нигезләрне билгеләү тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның гаризаларына үзгәрешләр кертү тәртибе.

Гаризаларны кабул итү вакыты: 2026 елның 14 сентябреннән 21 сентябренә кадәр.

2.2. Вәкаләтле орган тарафыннан Конкурс уздыруны гамәлдән чыгару турындагы белдерүне Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең өстәмә битендә (https://obrazovanie.kzn.ru) урнаштыру Конкурста катнашучылар тарафыннан гаризалар тапшыру вакыты тәмамланырга кимендә бер эш көне кала рөхсәт ителә.

Конкурс аны гамәлдән чыгару турындагы белдерү Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырылган көннән гамәлдән чыгарылган дип санала.

2.3. Конкурс гаризаларны читтән торып тикшерү һәм тапшырылган документларны бәяләү рәвешендә уздырыла.

Гаризаларны карап тикшерү һәм тапшырылган документларны бәяләү вакыты: 2026 елның 22 сентябреннән 28 сентябренә кадәр.

Конкурска нәтиҗәләр жюри әгъзалары утырышында, гаризаларны карап тикшереп, тапшырылган документларны бәяләү тәмамланганнан соң, ләкин 2026 елның 29 сентябреннән дә соңга калмыйча, беркетмәне имзалау юлы белән ясала.

Конкурс 2026 елның 29 сентябренә кадәр үткәрелә.

Беркетмәне рәсмиләштерү вакыты: Конкурс үткәрелгән көнне, 2026 елның 29 сентябреннән дә соңга калмыйча.

2.4. Конкурста катнашу өчен гариза бирүчеләр kazanobr.info@yandex.ru электрон почтасына «Яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә конкурс» тамгасы белән **.zip яки *.rar форматында архивлаштырылган бер файл белән түбәндәге материалларны юллый:

- әлеге Нигезләмәгә 1 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча Конкурста катнашу өчен гариза;

- 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча Конкурста катнашучының портфолиосы;

- 3 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

Конкурста катнашучы гаризада китерелгән мәгълүматның дөреслеге өчен җавап бирә.

2.5. Конкурсны оештыручы сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең өстәмә битендә (https://obrazovanie.kzn.ru) 2026 елның 29 сентябреннән дә соңга калмыйча урнаштыра.

## III. Конкурска нәтиҗәләр ясау, аның җиңүчесен һәм призерларны билгеләү

3.1. Конкурска нәтиҗәләр ясау, аның җиңүчесен һәм призерларны билгеләү Конкурс жюрие (алга таба – жюри) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2. Жюриның шәхси составы Вәкаләтле орган әмере белән раслана һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең өстәмә битендә (https://obrazovanie.kzn.ru) бастырыла.

Жюри составы рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән, жюри әгъзаларыннан гыйбарәт. Жюри әгъзалары составына кимендә биш кеше керә.

Жюри утырышын уздыру өчен кворум жюри әгъзалары санының яртысыннан да ким булмаска тиеш.

Конкурста катнашучыларның баллары тигез булса, карар жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

Жюри рәисе жюри эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, аның карарын раслый. Жюри рәисе булмаганда, аның функцияләрен жюри рәисе урынбасары башкара.

Жюри сәркатибе жюри рәисе йөкләмәсе буенча жюри утырышын әзерләүне оештыру функцияләрен гамәлгә ашыра.

3.3. Жюри әгъзасының җиңүчене билгеләгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган турыдан-туры яисә турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, ул, конкурс гаризаларын карап тикшерү башланганчы, бу хакта жюри рәисенә хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта әлеге жюри әгъзасы жюри эшендә катнашмый.

3.4. Жюри:

- конкурста катнашу өчен кабул ителгән документларны карап тикшерә;

- гаризаларны әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән критерийлар нигезендә бәяли;

- Конкурста җиңүчене һәм призерларны билгели.

3.5. Жюри карары катгый һәм үзгәртелми.

3.6. Конкурста җиңүчене һәм призерларны бүләкләү.

Конкурста җиңүче һәм призерлар Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы тарафыннан имзаланган дипломнар белән бүләкләнә.

## IV. Гаризаларны бәяләү һәм Конкурста җиңүчене һәм призерларны билгеләү тәртибе

4.1. Конкурс материалларын бәяләү критерийлары:

| № т/б | Бәяләү критерие | Баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Укыучыларның белем сыйфаты | 0-5 |
| 2 | Яшь педагогның белем бирү оешмасында апробацияләнгән үз методик системасы булу | 0-5 |
| 3 | Һөнәри осталык буенча төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашу | 0-5 |
| 4 | Педагогның һәм укучыларның педагоглар һәм яшьләр өчен конкурсларда, олимпиадаларда, конференцияләрдә, проектларда, ярышларда ирешкән казанышлары | 0-5 |
| 5 | Казан шәһәренең яшь педагоглары ассоциациясе эшендә катнашу | 0-5 |
| 6 | Төрле дәрәҗәдәге проектларда катнашу | 0-5 |
| 7 | Конференцияләрдә, түгәрәк өстәлләрдә, семинарларда һ.б. чыгыш ясау | 0-5 |
| 8 | Челтәр берләшмәләрендә басмалар булу, аларда эшләү | 0-5 |
| 9 | Квалификацияне күтәрү курсларын узу, башка белем бирү программаларында катнашу | 0-5 |

Һәр критерий биш баллы система буенча бәяләнә.

4.2. Жюри утырышы көнендә жюри сәркатибе жюри әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасы буенча катнашучыларның рейтингын формалаштыра.

4.3. Утырыш көнендә жюри әгъзалары Конкурста иң күп балл җыйган җиңүчеләрне билгели.

4.4. Конкурс нәтиҗәләре буенча, 2026 елның 29 сентябреннән дә соңга калмыйча, беркетмә төзелә. Ул утырышта катнашкан жюри әгъзалары тарафыннан имзалана, жюри рәисе яки аның урынбасары тарафыннан раслана.

Беркетмәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

- гаризаларны карап тикшерү көне, вакыты һәм урыны;

- Конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү көне, вакыты һәм урыны;

- гаризалары карап тикшерелгән Конкурста катнашучылар турында мәгълүмат;

- гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризаларның Конкурс уздыру турындагы белдерүнең кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган Конкурста катнашучылар турында мәгълүмат;

- Конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү эзлеклелеге, гаризаларны бәяләү өчен каралган һәр критерий буенча гаризаларга бирелгән баллар, мондый гаризаларга тәртип номерлары бирү турында гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән карарлар.

Беркетмә аны төзегән көннән алып бер көн эчендә Вәкаләтле орган тарафыннан Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең өстәмә битендә (https://obrazovanie.kzn.ru) урнаштырыла.

______________________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
Мәгариф идарәсе карамагындагы
муниципаль гомуми белем бирү
учреждениеләренең яшь педагогларын
укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә
конкурс уздыру тәртибе турында
нигезләмәгә 1 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә конкурста катнашу өчен гариза**

| **Фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Эш урыны** | **Вазифасы** | **Телефон номеры, электрон почта адресы** |
|---|---|---|---|
| | | | |

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 2 номерлы кушымта (Форма)

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә конкурста катнашучының портфолиосы**

| | |
|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Туу датасы | |
| Тулы яше | |
| Эш урыны, вазифасы | |
| Эш стажы | |

| № т/б | Күрсәткеч | Тасвирлама |
|---|---|---|
| 1 | Эшләү чорында педагог белем биргән укучылар ирешкән уңышлар. Укучыларның белем сыйфаты | |
| 2 | Яшь педагогның белем бирү оешмасында апробацияләнгән үз методик системасы | |
| 3 | Һөнәри осталык буенча төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашу | |
| 4 | Педагогның һәм укучыларның педагоглар һәм яшьләр өчен конкурсларда, олимпиадаларда, конференцияләрдә, проектларда, ярышларда ирешкән казанышлары | |
| 5 | Казан шәһәренең яшь педагоглары ассоциациясе эшендә катнашу | |
| 6 | өрле дәрәҗәдәге проектларда, социаль яктан әһәмияткә ия инициативаларда, педагоглар берләшмәләре чараларында катнашу, студентларның педагогик практикасын җитәкләү | |
| 7 | Конференцияләрдә, түгәрәк өстәлләрдә, семинарларда һ.б. чыгыш ясау | |
| 8 | Челтәр берләшмәләрендә басмалар булу, аларда эшләү | |
| 9 | Квалификация күтәрү курслары, башка белем бирү программалары | |

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 3 номерлы кушымта
(Форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ______________________________________________________________________,
(Конкурста катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)
паспорт _____________ __________________________________________ тарафыннан бирелгән,
(сериясе, номеры) (кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон таләпләре нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (алга таба – Мәгариф идарәсе) (420111, Казан шәһәре, Большая Красная урамы, 1 йорт), шул исәптән жюри һәм экспертларга Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри яктан үстерүгә конкурста катнашуга бәйле рәвештә ____________________________________________________________________
(Конкурста катнашучы эшли торган оешма атамасы)
һәм минем тарафтан бирелгән шәхси мәгълүматларны, аларны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңартуны, үзгәртүне), алуны, файдалануны, тапшыруны (бирүне, файдалану мөмкинлеген), шәхси үзенчәлекләрен юк итүне, тыюны, бетерүне, юкка чыгаруны кертеп, автоматлаштырылган режимда, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча эшкәртүгә, шул исәптән шәхси мәгълүматларның махсус категориясен эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Әлеге ризалык нигезендә эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар конкурста катнашу өчен гаризада һәм 2026 елда конкурста катнашуым белән бәйле рәвештә башка документларда китерелгән белешмәләрне үз эченә ала.

Әлеге ризалык 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә аны имзалаган көннән алып язма рәвештә кире алган көнгә кадәр гамәлдә.

Миңа Мәгариф идарәсенә минем тарафтан тапшырылган барлык белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплы булуым турында хәбәр ителде.

Шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта Мәгариф идарәсенә ун көн эчендә хәбәр итәргә йөкләмә алам.

Ризалык биргәндә, үз теләгем белән һәм үз мәнфәгатьләремдә эш итүемне раслыйм.

Миңа шәхси мәгълүматларның Мәгариф идарәсе тарафыннан автоматлаштырылмаган һәм автоматлаштырылган эшкәртү ысулы белән эшкәртеләчәге турында хәбәр ителде.

20_____ елның «_____» ________________ ______________/____________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)